РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

11.02.2020 | № 200-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районының муниципаль мәгариф
учреждениеләренә карата Гамәлгә куючының
аерым вазифаларын һәм вәкаләтләрен
тапшыру һәм чикләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәгариф системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру, мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында, Башкарма комитет

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләренә карата Гамәлгә куючының аерым вазифаларын һәм вәкаләтләрен тапшыру һәм чикләү турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” Муниципаль казна учреждениесе башлыгына (И.Ф. Шакиров) һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге Карарның 1 пункты белән расланган муниципаль мәгариф учреждениеләрен Гамәлгә куючының аерым вазифаларын һәм вәкаләтләрне чикләү турындагы Нигезләмәгә таянып эш итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” Муниципаль казна учреждениесе башлыгы И.Ф. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрен Гамәлгә куючының аерым вазифаларын һәм вәкаләтләрен чикләү турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Нигезләмә “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында мәгариф системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру, мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты һәм “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” Муниципаль казна учреждениесе, муниципаль берәмлекнең муниципаль бюджет учреждениесе арасында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләрен Гамәлгә куючының аерым вазифаларын һәм вәкаләтләрен чикли, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләре компетенциясен тасвирлый.

## 2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Башкарма комитеты вәкаләтләре.

2.1. Муниципаль мәгариф учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору, ябу, муниципаль мәгариф учреждениеләрен Гамәлгә куючыларның вазифаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.

2.2. Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны карау һәм тәрбияләү, балаларны карап тоту өчен шартлар тудыру.

2.3. Муниципаль мәгариф учреждениеләре биналарын һәм корылмаларын карап тотуны тәэмин итү, алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү.

2.4. Муниципаль мәгариф учреждениеләре уставын, шулай ук аңа кертелә торган үзгәрешләрне раслау.

2.5. Муниципаль мәгариф учреждениесенә Гамәлгә куючы тарафыннан беркетелгән яки муниципаль мәгариф оешмасы тарафыннан мондый мөлкәт сатып алуга (алга таба – аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт) гамәлгә куючы тарафыннан

бүлеп бирелгән акчалар хисабына сатып алынган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт төрләрен һәм исемлеген билгеләү.

2.6. Муниципаль мәгариф учреждениесе тарафыннан “Коммерцияле булмаган оешмалар турында” Федераль законның 9.2 маддәсендәге 13 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килә торган эре килешүләрне башкаруны алдан килештерү.

2.7. “Коммерциячел булмаган оешмалар турында” Федераль законның 27 статьясында билгеләнгән критерийлар нигезендә билгеләнә торган муниципаль мәгариф учреждениесе катнашындагы һәм аларны башкаруда кызыксыну булган килешүләрне хуплау турында карарлар кабул итү.

2.8. Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәя билгеләү.

2.9. Муниципаль мәгариф учреждениесенә Гамәлгә куючы тарафыннан беркетелгән яки муниципаль мәгариф оешмасы тарафыннан мондый мөлкәт сатып алуга гамәлгә куючы тарафыннан бүлеп бирелгән акчалар хисабына сатып алынган аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт белән эш итүне килештерү.

2.10. Муниципаль мәгариф учреждениесе тарафыннан күчемсез мөлкәт белән эш итүне килештерү, шул исәптән аны арендага бирү.

2.11. Муниципаль мәгариф учреждениеләрен ТР Саба муниципаль районының конкрет территорияләренә беркетү.

2.12. Саба муниципаль районы территориясендә яшәүче һәм мәгариф оешмаларында мәҗбүри укырга тиешле балаларның исәбен алып бару тәртибен раслау.

2.13. Муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен муниципаль йөкләмәне раслый һәм аны финанслауны тәэмин итә.

2.14. Ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) балаларны муниципаль мәгариф учреждениеләрендә карау һәм тәрбияләү өчен алына торган түләүне билгеләү һәм аның күләме.

2.15. Саба муниципаль районы территориясендә мәгарифне үстерү программасын раслау.

2.16. Муниципаль мәгариф учреждениесе эшчәнлегенең төп төрләренә караган, аларга билгеләнгән муниципаль биремнән тыш күрсәтелә торган хезмәтләр (эшләр) өчен, шулай ук федераль законнарда билгеләнгән очракларда, билгеләнгән муниципаль йөкләмә чикләрендә физик һәм юридик затлар өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен һәм күләмнәрен билгеләү.

2.17. Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә учреждениегә беркетелгән муниципаль мөлкәтне файдалану турындагы хисапны төзү һәм раслау тәртибен билгеләү.

2.18. Муниципаль мәгариф учреждениесе тарафыннан, федераль законнарда каралган очракларда, акчаларны, аерым кыйммәтле күчемле мөлкәттән тыш башка мөлкәтне, шулай ук күчемсез мөлкәтне, (әгәр аларны бирү шартлары башкача билгеләнмәгән булса) хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталына (җыелма) кертүне яисә әлеге мөлкәтне гамәлгә куючы яисә катнашучы буларак башка рәвештә тапшыруны килештерү.

2.19. Муниципаль мәгариф учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә төзү һәм раслау тәртибен билгеләү.

2.20. Эш бирүче инициативасы буенча Учреждение җитәкчесе белән хезмәт шартнамәсен өзүгә китерә торган муниципаль мәгариф учреждениесенең срогы

чыккан кредиторлык бурычының иң чик мөмкин булган кыйммәтен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә килештерү.

2.21. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУ җитәкчесен билгеләү (раслау) һәм аның вәкаләтләрен туктату.

2.22. Мәгариф өлкәсендә халыкара, төбәкара һәм муниципальара хезмәттәшлекне үстерү.

## 3.“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе вәкаләтләре

3.1. Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш) оештыра.

3.2. Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларга өстәмә белем бирүне (финанс белән тәэмин ителеше Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыра.

3.3. Муниципаль мәгариф системасына гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра һәм системаның барлык структураларының эшчәнлеген координацияли.

3.4. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балалар исәбен алып бара.

3.5. Муниципаль белем бирү учреждениеләре тарафыннан юридик һәм физик затлар тарафыннан Башкарма комитет белән килештереп муниципаль хезмәт күрсәтү (эшләр башкару) өчен муниципаль йөкләмә формалаштыра һәм муниципаль берәмлекнең ведомство буйсынуындагы учреждениеләре тарафыннан муниципаль биремнең үтәлешен контрольдә тота.

3.6. Мәгариф хезмәткәрләренең, балалар һәм яшүсмерләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итә, аларны укытуны, мәшгульлеген һәм ялын оештыру, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен шартлар тудыра.

3.7. Белем бирү һәм тәрбия процессының өзлексезлеген, аларның сыйфатлы үсешен җәмгыять ихтыяҗларына туры китереп, милли-региональ үзенчәлекләрне исәпкә алып тәэмин итә.

3.8. Алты яшь һәм алты айга җитмәгән яки 8 яшьтән өлкәнрәк булган балаларны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укыту өчен муниципаль мәгариф учреждениеләренә кабул итүгә рөхсәт бирә.

3.9. Саба муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре җитәкчеләрен билгеләү (раслый) һәм аларның вәкаләтләрен туктату.

3.10. Саба муниципаль районы муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре белән хезмәт килешүләрен төзи һәм өзә.

3.11. Тәрбия эше системасын оештыра, муниципаль белем бирү учреждениеләрендә психологик хезмәт эшен координацияли.

3.12. Муниципаль мәгариф системасының кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыра, педагогик һәм җитәкче кадрларны аттестацияләү эшен оештыра.

3.13. Муниципаль белем бирү учреждениеләрендә белем бирүнең сыйфатын күтәрүгә, педагогик фәннең заманча таләпләренә туры килә торган прогрессив белем бирү технологияләрен үзләштерүгә ярдәм итә торган шартлар тудыра.

3.14. Мәгариф өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне үстерә.

3.15. Укучыларның һәм мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең туклануын оештыруны тәэмин итә.

3.16. Белем бирү оешмаларын мәгълүмат белән тәэмин итүне оештыра, инновацион белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларына акча бирә.

3.17. Идарә компетенциясе өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында, шулай ук ведомство карамагындагы учреждениеләр һәм үз ихтыяҗлары өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелә торган контрактлар буенча муниципаль заказчы сыйфатында катнаша.

3.18. Гражданнарның туган телдә белем алу хокукларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыра.

3.19. Эшчәнлеге мәгариф мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелгән Саба муниципаль районында сәламәтләндерү учреждениеләре (лагерьлар) һәм башка оешмалар булдыруга һәм эшләүгә ярдәм итә;

3.20. Билгеләнгән тәртиптә мәгариф өлкәсендә дәүләт статистика хисаплылыгын җыю, эшкәртү, анализлауны һәм тапшыруны гамәлгә ашыра.

3.21. Билгеләнгән вакытка Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәгариф учреждениеләре идарәсе карамагындагы бюджет һәм бюджеттан тыш эшчәнлек буенча статистик һәм бухгалтерлык хисабын тәкъдим итә.

3.22. Идарә компетенциясе белән бәйле бәхәсләр буенча судларда, шул исәптән Саба муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән дә катнаша.

3.23. Мәгариф идарәсе вәкаләтләренә шулай ук түбәндәгеләр керә:

- җирле үзидарә органнарына законда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган мәгариф өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләү;
- Федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә мәгариф өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшен оештыру;
- Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль белем бирү учреждениеләренең укыту-методик һәм тәрбия эшчәнлеген алып баруны һәм координацияләүне гамәлгә ашыру;
- Саба муниципаль районы территориясендә белем бирү учреждениеләре челтәрен үстерү, контрольдә тоту һәм координацияләү;
- мәгариф өлкәсендә муниципаль программаларны һәм проектларны, аларны финанс белән тәэмин итү мәсьәләләреннән тыш, эшләү һәм тормышка ашыру эшчәнлеген оештыру;
- гражданнарны кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карау, алар буенча үз вәкаләтләре чикләрендә кирәкле чаралар күрү;
- төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыру һәм үткәрү;
- дәрестән тыш һәм каникул вакытында укучыларның ялын, сәламәтләндерүне, хезмәт һәм мәшгульлеген оештыру;
- муниципаль белем бирү учреждениеләрен төзү, үзгәртеп кору, ябу эшләрен координацияләү;
- муниципаль белем бирү учреждениеләре ихтыяҗлары өчен биналар һәм объектларны төзү, агымдагы һәм капиталь ремонт буенча тәкъдимнәр кертү;

- белем алу өчен социаль-икътисади шартлар тудыру, кешенең ботен тормыш юлы буенча төрле дәрәҗәдәге һәм төрле юнәлештәге белем алуга булган ихтыяҗын канәгатьләндерү мөмкинлекләрен киңәйтү.;
- балигъ булмаган балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) балаларны тәрбияләүдә, аларның физик һәм психик сәламәтлеген саклауда һәм ныгытуда, индивидуаль сәләтләрне үстерүдә һәм аларның үсешендәге кимчелекләрне төзәтүдә ярдәм күрсәтү;
- мәгариф системасы турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү;
– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәгариф системасы мониторингын оештыруны тормышка ашыру;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының мәгариф торышы һәм үсеш перспективалары турында йомгаклау (еллык) отчетларын “Электрон Мәгариф” Татарстан Республикасы рәсми сайты битендә ел саен бастырып чыгару һәм урнаштыру;
- муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә финанс һәм матди чараларның керүе һәм аларны тоту турында еллык хисапларны, шулай ук үз-үзеңне тикшерү нәтиҗәләре турында хисапларны бирү һәм урнаштыруны координацияләү;
- төп гомуми һәм урта гомуми белем турында дәүләт үрнәгендәге документлар бланкларын, уку турында таныклык һәм аларның дубликатларын, “Укудагы аерым уңышлары өчен” медальләрен алу, саклау, бирү һәм исәпкә алу;
- гомуми белем бирү оешмаларына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга төп гомуми һәм урта гомуми белем турында аттестатлар дубликатларын бирү вәкаләтләрен тапшыру;
- мәгариф оешмаларында укытылырга тиешле,ләкин белем алмаучы балалар, шул исәптән гаилә формасын яисә үзлегеңнән белем алу рәвешен сайлаган балаларның реестрын алып бару;
- муниципаль белем бирү учреждениесе эшчәнлеге туктатылган , лицензия юкка чыккан, үзгәргән, гамәлдән чыккан очракларда балигъ булган укучыларны аларның ризалыгы белән һәм балигъ булмаган укучыларны аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән башка муниципаль мәгариф учреждениеләренә күчерүне тәэмин итү;
- төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләренә укучыларны җирлекләр арасында түләүсез йөртүне координацияләү;
- Саба муниципаль районы территориясендә мәгариф өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыруда, мәгариф белән идарә итү системасын, мәгарифне карап тоту һәм технологияләрен камилләштерүдә, муниципаль мәгариф системасын үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен эшләүдә һәм тормышка ашыруда катнашу;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль хокукый актларда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.
– муниципаль белем бирү учреждениеләрендә белем бирү процессының мәгълүмати-методик тәэмин ителеше, укыту-методик һәм тәрбия эше анализы үткәрү һәм аларның эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- муниципаль мәгариф учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә һөнәри осталыкны арттыруда мәгълүмати-методик ярдәм күрсәтү;

- муниципаль мәгариф учреждениеләрендә инновацион эшчәнлекне оештыруда катнашу;
- педагогик тәҗрибәне анализлау һәм бәяләүне гамәлгә ашыру;
– муниципаль белем бирү учреждениеләре өчен бердәм белем бирү (методик) киңлеге кысаларында кирәкле консультация системасы булдыру;
- педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләр резервының мәгълүмат базасын формалаштыру;
- педагогик хезмәткәрләргә, муниципаль мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренә инновацион эш алып баруда, программаларны, пособиеләрне, уку планнарын эксперт бәяләвендә, мәгариф хезмәткәрләрен аттестацияләүгә әзерләүдә методик ярдәм күрсәтү эшен оештыру ;
- муниципаль белем бирү учреждениеләре һәм педагоглар эшчәнлегенең уңай тәҗрибәсен массакүләм мәгълүмат чаралары һәм "Интернет" челтәре аша тарату;
- фәнни-педагогик конференцияләр, смотр-конкурслар әзерләүдә һәм уздыруда катнашу;
- муниципаль мәгариф учреждениеләре педагогик хезмәткәрләренең муниципаль методик берләшмәләре эшен оештыру;
- муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләрен арадаш һәм йомгаклау дәүләт аттестациясен уздыруга әзерләүне методик озата баруны гамәлгә ашыру;
- муниципаль белем бирү учреждениеләрендә дәреслекләр, укыту-методик әдәбият фондларын комплектлауны тәэмин итү;
- муниципаль белем бирү учреждениеләре укучыларының һәм тәрбияләнүчеләренең фестивальләр, конкурслар, фән олимпиадалары, конференцияләрен оештыру һәм үткәрү;
- үз карамагындагы муниципаль белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген координацияләү һәм аларны матди-техник тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм итү;
- белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүне гамәлгә ашыру;
- җирле бюджетның бюджет ассигнованиеләре хисабына укучыларны тукландыруны тәэмин итү тәртибен билгеләү;
- мәгариф системасында аерым уңышлары һәм казанышлары өчен муниципаль мәгариф учреждениеләре һәм физик затлар өчен махсус акчалата бүләкләр билгеләү;
– муниципаль белем бирү учреждениеләренең аларга бүлеп бирелә торган бюджет акчаларын куллануны тикшереп тору;
- гамәлдәге законнар нигезендә муниципаль белем бирү учреждениеләренең тиешле шәхси счетларында чагылдырылган операцияләр буенча мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итү;
– муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен бүләкләү һәм аларга дисциплинар җәза бирү турында Карар кабул итә.

## 4. Муниципаль мәгариф оешмалары компетенциясе.

4.1. Муниципаль белем бирү учреждениеләре компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

– укучыларның эчке тәртип кагыйдәләрен, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен һәм башка локаль норматив актларны эшләү һәм кабул итү;

– белем бирү эшчәнлеген, бүлмәләрне җиһазлауны таләпләр нигезендә, шул исәптән федераль дәүләт белем бирү стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, белем бирү стандартлары нигезендә матди-техник яктан тәэмин итү;

- ел саен “Интернет” челтәрендә финанс һәм матди чараларның керүе һәм аларны тоту һәм үз-үзеңне тикшерү нәтиҗәләре турында хисап урнаштыру;

- хезмәткәрләрне кабул итү һәм эштән азат итү, алар белән хезмәт килешүләрен төзү һәм өзү; вазыйфаи бурычларны бүлү, хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрүгә шартлар тудыру һәм ярдәм итү;

- мәгариф учреждениесенең белем бирү программаларын эшләү һәм раслау;

- муниципаль белем бирү учреждениеләренә укучыларны кабул итү;

- башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы учреждениеләр тарафыннан дәүләт тарафыннан аккредитацияләнгән уку-укыту программаларын гамәлгә ашырганда файдалануга тәкъдим ителгән дәреслекләрнең расланган федераль исемлеге нигезендә дәреслекләр исемлеген, шулай ук күрсәтелгән белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда мондый учреждениеләр тарафыннан файдалануга җибәрелгән уку пособиеләрен билгеләү;

- укучыларның өлгерешенә һәм арадаш аттестациясенә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру, аларның формасын, вакытын һәм үткәрү тәртибен билгеләү;

- укучыларның белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләрен индивидуаль исәпкә алуны гамәлгә ашыру, шулай ук архивларда бу нәтиҗәләр турында кәгазь һәм (яки) электрон чыганакларда мәгълүмат саклау;

- укыту һәм тәрбия, белем бирү технологияләрен, электрон укыту методларын куллану һәм камилләштерү;

- белем бирү сыйфатын бәяләүнең эчке системасы эшчәнлеген тәэмин итү, үз-үзеңне тикшерүне үткәрү;

- сәламәтлек саклау һәм ныгыту өчен кирәкле шартлар тудыру, укучыларның һәм муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең туклануын оештыру;

- мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә наркотик һәм психотроп матдәләрне законсыз куллануны алдан ачыклау максатларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрүне оештыру.;

- укучыларга физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру.;

- укучыларның киеменә һәм тышкы кыяфәтенә карата таләпләрне билгеләү;

- мәгариф учреждениесендә гамәлгә ашырыла торган һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган балигъ булмаган балаларның, ата-аналарының (законлы вәкилләренең) иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә булышлык күрсәтү;

- фәнни-методик эшне оештыру, шул исәптән фәнни һәм методик конференцияләр, семинарлар оештыру һәм үткәрү;
- “Интернет” челтәрендә мәгариф оешмасының рәсми сайтын булдыру һәм алып баруны тәэмин итү;
- белем бирү программаларының тулы күләмдә гамәлгә ашырылуын, укучыларны әзерләү сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүен, кулланыла торган формаларның, чараларның, тәрбиянең яшь, психофизик үзенчәлекләренә, һәвәслекләренә, сәләтләренә, мәнфәгатьләренә һәм ихтыяҗларына туры килүен тәэмин итү;
- укучыларны укытуның, тәрбияләүнең ,шулай ук аларны карау һәм тәрбияләүнең, белем алучыларның, мәгариф учреждениесе хезмәткәрләренең тормышын һәм сәламәтлеген билгеләнгән нормалар нигезендә тәэмин итүнең куркынычсыз шартларын булдыру ;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, Муниципаль хокукый актлар яки учреждение Уставы нигезендә компетенциянең башка мәсьәләләре.